Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Кадер авыл җирлегенең Федот торак пунктында
2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**21.11.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Федот торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кадер авыл җирлеге Федот торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- Үзәк урамы буенча торак пункт эчендәге юлларга вак таш җәю.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырырга, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында (Кадер авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) урнаштырырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Кадер авыл җирлеге башлыгы** **Л.Н. Барсукова**